СОВЕТ НУРИНЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ НӨНӘГӘР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ
27 сентябрь 2024 ел

КАРАР
№ 110

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Нөнәгәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең «Бюджет процессы турында» Нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында**

Бюджет законнарына туры китерү максатларында Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Нөнәгәр авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Нөнәгәр авыл җирлеге Советының 11.11.2019 ел № 124 карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Нөнәгәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең «Бюджет процессы турында» нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4 статьяның 6 пунктында:

- 10 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10) максатчан билгеләнештәге бюджетара субсидияләрне, субвенцияләрне һәм башка бюджетара трансфертларны, шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән башка субсидияләрне һәм бюджет инвестицияләрен, аларны биргәндә билгеләнгән шартларны, максатларны һәм тәртипне алучылар тарафыннан үтәүне тәэмин итә;»;

- 11 пунктчаны үз көчен югалткан дип танырга; - 13 пунктчада «муниципаль район» сүзләрен «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Нөнәгәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге» сүзләренә алмаштырырга;

- түбәндәге эчтәлекле 13.1 пунктча өстәргә:

«13.1) «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең интеграцияләнгән мәгълүмат системасында капиталь төзелеш объектлары һәм күчемсез мөлкәт объектлары турында белешмәләр, федераль бюджет акчалары (объектлардан тыш) булган капитал салуларны финанс белән тәэмин итү (финанслашу) чыганагы формалаштыра »

1.2. 4 статьяның 7 пунктына түбәндәге эчтәлекле 5 пункытча өстәргә:

«5) максатчан билгеләнештәге бюджетара субсидияләрне, субвенцияләрне һәм башка бюджетара трансфертларны, шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән башка субсидияләрне һәм бюджет инвестицияләрен, аларны биргәндә билгеләнгән шартларны, максатларны һәм тәртипне алучылар

тарафыннан үтәүне тәэмин итә.»;

1.3. 4 статьяның 9 пунктында:

- 6 пунктчада «түләнергә тиешле сумманы исәпләгән көннән дә соңга калмыйча» сүзләрен өстәргә;

- 7 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7) бюджетка түләүләр буенча бурыч түләүгә ышанычсыз дип тану турында карар кабул итә;»;

- түбәндәге эчтәлекле 8 һәм 9 пунктлар өстәргә:

«8) Россия Федерациясе Финанс министрлыгы билгеләгән гомуми таләпләр нигезендә эшләнгән бюджет, пенялар һәм штрафлар буенча дебитор бурычларын түләтү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру регламентын билгели;

9) Россия Федерациясе Бюджет кодексында һәм анын нигезендә кабул ителә торган, бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган муниципаль хокукый актларда билгеләнгән бүтән бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыра.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы (baltasi.tatarstan.ru) составында Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Нөнәгәр авыл
җирлеге башлыгы: И.Н.Закиров